**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Аксубай муниципаль районы**
**Яңа Ибрай авыл җирлеге**
423079 Яңа Ибрай авылы
Совет урамы, 5 йорт тел. (факс)
884344- 4-27-27

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Совет Новоибрайкинского**
**сельского поселения**
**Аксубаевского муниципального**
**района**
423079 с.Новое Ибрайкино
улица Советская, д.5

КАРАР

№ 37 — 2022 елның 29 нчы марты

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге Советының «Җирлекнең муниципаль хезмәте һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге башлыгына муниципаль хезмәткәрләргә квалификация разрядларын бирү процедурасын үткәрү вәкаләтләрен бирү турында нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 5 августындагы 10 нчы номерлы карарын үз көчен югалткан дип тану хакында.

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Яңа Ибрай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге Советы
КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге Советының «Җирлекнең муниципаль хезмәте һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге башлыгына муниципаль хезмәткәрләргә квалификация разрядларын бирү процедурасын үткәрү вәкаләтләрен бирү турында нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 5 августындагы 10 нчы номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
2. Яңа Ибрай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aksubayevo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Яңа Ибрай авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе — Ф.Х.Кәбиров